МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.10.2016 г. Казань № 896 од

Татарстан Республикасында Театрлар реестры турында нигезләмәне раслау турында

«Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында» 2016 елның 11 июнендәге 43-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасында театр сәнгатенә ярдәм итү һәм театр сәнгатен үстерү дәүләт программаларын әзерләгәндә башкару максатларында

БОЕРАМ:

1. Татарстан Республикасында Театрлар реестры турында теркәлгән нигезләмәне расларга
2. Һөнәри сәнгать һәм сәнгати белем бирү бүлегенә (Д.Ф.Хәйретдинова) Татарстан Республикасы театрлары реестрын алып бару эшен оештырырга.
3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Министр А.М.Сибагатуллин

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
2016 елның „18" 10 896од номерлы
боерыгы белән расланган

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕАТРЛАРЫ РЕЕСТРЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Нигезләмә «Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында» 2016 елның 11 июнендәге 43-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына нигезләнеп әзерләнгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән дәүләти, муниципаль һәм хосусый театрлар турында бердәм мәгълүмат базасы булдыруны оештыру һәм хисап алып бару буенча Татарстан Республикасы театрлары реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләрен билгели (алга таба – Реестр, Театр).

1.2. Реестрны формалаштыру һәм алып баруны, театрлар һәм театр эше турында закон таләпләрен үтәп, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – Министрлык) гамәлгә ашыра.

1.3. Реестр агымдагы елның 1 гыйнвардагы торышы буенча үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелеп, агымдагы елның 15 мартыннан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы боерыгы белән раслана.

1.4. Әлеге боерыкта «театр» төшенчәсе Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 10 июнендәге 1019-р номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә 2020 елга кадәр озак вакытлы театр эше үсеше концепциясендә билгеләнгән мәгънәдә кулланыла.

## II. ТЕАТР ТУРЫНДАГЫ МӘГЪЛҮМАТНЫ РЕЕСТРГА КЕРТҮ ТӘРТИБЕ

2.1. Театр турындагы мәгълүматны Реестрга кертү өчен Театр җитәкчесе, гамәлгә куючы белән бергә килештереп, Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Реестрга Театр турында мәгълүмат кертү турында гариза (1 нче кушымта);

Театрның хисап карточкасы (2 нче кушымта);

Театрны гамәлгә кую документлары күчермәләре;

юридик затны дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе;

Театрның штат расписаниесе күчермәсе.

2.2. Театр турында мәгълүматны Реестрга кертү турында гариза һәм аңа теркәлгән документлар Театр вәкилләре тарафыннан Министрлыкка түбәндәге адрес буенча юллана: 420015, Казан ш., Пушкин ур., 66/33 й.

2.3. Театр турында мәгълүматны Реестрга кертү яки баш тарту турында карар Министрлык тарафыннан 30 көн эчендә кабул ителә.

2.4. Театр турында мәгълүматны Реестрга кертүдән баш тартуга түбәндәгеләр нигез булып тора:

Нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларның тулы җыелмасын китермәү;

оешма тормышка ашырган эшчәнлек төрләренең театрлар эшчәнлеге төрләренә туры килмәве.

Әлеге нигезләмәнең 2.3 пунктында күрсәтелгән вакытта гариза бирүчегә юллана торган Театр турында мәгълүматны реестрга кертүдән баш тарту турында белдерү кәгазендә баш тартуның дәлилләре китерелә.

Театр турында мәгълүматны реестрга кертүдән баш тарту Театр җитәкчесенә Театр турындагы мәгълүматны Реестрга кертү өчен Нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны яңадан тапшыруга тоткарлык тудырмый.

2.5. Реестр әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасында китерелгән формада формалаштырыла һәм Министрлыкта кәгазь нөсхәдә һәм электрон рәвештә саклана.

2.6. Реестр даими саклана тиешле документ булып тора.

## III. ТЕАТРНЫҢ РЕЕСТР ТАЛӘПЛӘРЕНӘ ТУРЫ КИЛҮЕН РАСЛАУ ТӘРТИБЕ

3.1. Реестрга кертелгән театр ел саен, отчет елыннан соң килгән елның 1 февраленә кадәрге вакыт эчендә, театрның бәяләмәсе һәм эшчәнлеге турында алдан бирелгән документларга туры килүен раслый.

3.2. Реестрга кертелгән мәгълүматлар үзгәрә калса, театр җитәкчесе гамәлгә куючы белән килештереп 5 көн эчендә Министрлыкка язмача хәбәр итә.

3.3. Гамәлгә кую документларына үзгәрешләр кертелгән очракта Театр 30 көн вакыт эчендә Театрны гамәлгә куючы тарафыннан расланган гамәлгә кую документларының күчермәләрен тапшыра.

Татарстан Республикасында
Театрлар реестры турында
нигезләмәгә 1 нче кушымта

Театрны Татарстан Республикасында театрлар реестрына кертү турында
ГАРИЗА ФОРМАСЫ

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгына
______________________
(театр җитәкчесе)

ГАРИЗА

«Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында» 2016 елның 11 июнендәге 43-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының ____________________ ______ номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында Театрлар реестры турында нигезләмәгә нигезләнеп
Реестрга кертүегезне сорыйм _______________________________________________________
(гамәлгә кую документлары нигезендә театрның атамасы).

Соралган документлар җыелмасы теркәлә.
Кушымта:
1. Театрны гамәлгә кую документлары күчермәсе, ___ б., ___ нөсхә.
2. Юридик затны дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе, __ б. ___ нөсхә.
3. Театрның штата расписаниесе күчермәсе, ___ б. ___ нөсхә.
4. Театр афишасы.

Театр җитәкчесе

(имза) (имзаны шәрехләү)

Дата

Татарстан Республикасында
Театрлар реестры турында
нигезләмәгә 2 нче кушымта

## Театрның хисап карточкасы

<table>
<tr><td>1.</td><td colspan="2">Театрның тулы һәм кыскартылган атамасы</td><td></td></tr>
<tr><td>2.</td><td colspan="2">Театрның юридик һәм фактик адресы</td><td></td></tr>
<tr><td>3.</td><td colspan="2">Театрны оештыру датасы</td><td></td></tr>
<tr><td>4.</td><td colspan="2">Театрның оештыру-хокукый формасы: гамәлгә кую документлары</td><td></td></tr>
<tr><td>5.</td><td colspan="2">Театрны гамәлгә куючы (атамасы, почта адресы, телефон, факс (код белән), электрон почта адресы, җаваплы хезмәткәрнең Ф.И.ӘИ. һәм вазыйфасы)</td><td></td></tr>
<tr><td>6.</td><td colspan="2">Театр белән элемтә өчен мәгълүмат (почта адресы, телефон, факс (код белән), электрон почта адресы, интернет-вәкиллек (сайт)</td><td></td></tr>
<tr><td>7.</td><td colspan="2">Стационар бина булу-булмавы</td><td></td></tr>
<tr><td>8.</td><td colspan="2">Театр җитәкчесенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (директорның, режиссерның) һәм аның белән элемтә өчен мәгълүмат (телефон, электрон почта адресы)</td><td></td></tr>
<tr><td>9.</td><td colspan="2">Театр структурасы (административ-идарә аппараты, бүлекләр исемлеге)</td><td></td></tr>
<tr><td>10.</td><td colspan="2">Хезмәткәрләр саны (кеше)</td><td></td></tr>
<tr><td>11.</td><td colspan="2">Шулар арасыннан сәнгати-артистлар өлеше</td><td></td></tr>
<tr><td>12.</td><td rowspan="2">Тамаша залының (мәйданчыкның) сыйдырышлылыгы (урын)</td><td>төп</td><td></td></tr>
<tr><td>13.</td><td>өстәмә</td><td></td></tr>
<tr><td>14.</td><td rowspan="4">Сәхнәнең төп параметрлары</td><td>Сәхнә көзгесе (м.)</td><td></td></tr>
<tr><td>15.</td><td>Колосникларга кадәр биеклек (м.)</td><td></td></tr>
<tr><td>16.</td><td>Әйләнә (диаметр (м.)</td><td></td></tr>
<tr><td>17.</td><td>Оркестр чокыры тирәнлеге (м.) *</td><td></td></tr>
<tr><td>18.</td><td rowspan="2">Куелган тамашалар саны</td><td>Репертуарда яңа куелышлар саны</td><td></td></tr>
<tr><td>19.</td><td>Отчет елында куелышлар саны</td><td></td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| 20. | | Отчет елында тулысынча яңартылган куелышлар саны | |
| 21. | Чаралар/спектакльләр саны (ед.) | Бер айда | |
| 22. | | Бер елда | |
| 23. | | Шул исәптән бер айда балалар өчен | |
| 24. | | Шул исәптән бер елда балалар өчен | |
| 25. | Билетларның бәя чикләре | | |
| 26. | Театрның эш режимы | | |
| 27. | Кушымталар:<br>1. Тамаша залы планы<br>2. Сәхнә планы | | |

* булса

Татарстан Республикасында
Театрлар реестры турында
нигезләмәгә 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы театрлары реестры

| № | **Юридик зат атамасы** | **Җитәкченең һәм/яисә баш режиссерның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме** | **Учреждениенең адресы** | **Төзелгән елы** | **Реестрда тәртип номеры** |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | |
| | Дәүләт театрлары | | | | |
| 1. | | | | | |
| | Муниципаль театрлар | | | | |
| 1. | | | | | |
| | Хосусый театрлар | | | | |
| 1. | | | | | |